| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СТАРОГРИШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>Ул.Молодежная, д.1, с.Старое Гришкино,<br>Менделеевский район, Республика<br>Татарстан, 423642 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ИСКЕ ГРИШКИН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>Яшьләр ур, 1 йорт,<br>Иске Гришкин авылы, Менделеевск<br>районы,<br>Татарстан Республикасы,423642 |

Тел. (факс): (85549) 3-51-18
e-mail: Sgr.Men@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.12.2024 ел № 58

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
Иске Гришкино авыл җирлеге муниципаль
берәмлегенең җирдән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләре проекты буенча
ачык тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Иске Гришкино авыл җирлеге Уставы, ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә ярашлы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 10 гыйнвары 17.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Менделеевск районы Иске Гришкино авылы, Яшьләр ур., 1 йорт адресы буенча урнашкан Иске Гришкино авыл мәдәният йорты бинасының актлар залында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Иске Гришкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Алексеев К.И. – Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы;

Гасанов О.А.- Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Советы рәисе урынбасары;

Мамакова В.В. – Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге депутаты.

3. 2024 елның 9 декабреннән 2025 елның 10 гыйнварына кадәр «Иске Гришкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча материаллар экспозициясен Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Иске Гришкино авылы, Яшьләр урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында оештырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): 423653, Татарстан

Республикасы, Менделеевск районы, Иске Гришкино авылы, Яшьләр урамы, 1 йорт (Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы исеменә).

5. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендәге Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendsleevsk.tatar.ru . «Иске Гришкино авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үземдә калдырам.

Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы К.И.Алексеев